# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Көек авыл җирлеге Яңа Шимбер торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

“22” ноябрь 2020 ел. № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2020 елның 22 ноябрендә «Сез 2021 елда Түбән Көек авыл җирлеге Яңа Шимбер торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчегә, 500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

1. Территорияне төзекләндерү һәм чистарту:

- Яңа Шимбер авылы территориясен чистарту, агач һәм куаклар кисү, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү;

- урам яктырткычларына хезмәт күрсәтү (яктырткычлар, үткәргечләрне ремонтлау, лампаларны алыштыру) һәм яктырткычлар сатып алу.

2. Беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү:

- Яңа Шимбер авылында гадәттән тыш хәлләр вакытында су белән тәэмин итү системасының өзлексез эшләве өчен генератор урнаштыру өчен төзелеш материаллары, җиһазлар сатып алу һәм хезмәтләр өчен түләү;

- янгын гидранты өчен колонка сатып алу;

- су алу урыннарын төзекләндерү (төзелеш материаллары сатып алу һәм хезмәтләр өчен түләү) Экономия ясалган очракта, аерым мәсьәләләр буенча Түбән Көек авыл җирлеге башкарма комитетына җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итү өчен акча җибәрергә рөхсәт итәргә.

«РИЗА» «КАРШЫ»

мәсьәләсе буенча халык җыены нәтиҗәләре белән беркетмә төзелде.

Халык җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 44 (кырык дүрт) кеше кертелгән, җыенда катнашучылар саны 30 (утыз) кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

"Әйе» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 44 (кырык дүрт) кеше тавыш бирде;
«Юк» позициясе өчен җыенда катнашучыларның 0 (ноль) тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Көек авыл җирлеге Яңа Шимбер авылында узган халык җыенын - узган дип, халык җыены нәтиҗәләрен – дөрес дип танырга.

“Сез 2021 елда Түбән Көек авыл җирлеге Яңа Шимбер торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчегә, 500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме: -

1. Территорияне төзекләндерү һәм чистарту:

- Яңа Шимбер авылы территориясен чистарту, агач һәм куаклар кисү, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү;

- урам яктырткычларына хезмәт күрсәтү (яктырткычлар, үткәргечләрне ремонтлау, лампаларны алыштыру) һәм яктырткычлар сатып алу.

2. Беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү:

- Яңа Шимбер авылында гадәттән тыш хәлләр вакытында су белән тәэмин итү системасының өзлексез эшләве өчен генератор урнаштыру өчен төзелеш материаллары, җиһазлар сатып алу һәм хезмәтләр өчен түләү;

- янгын гидранты өчен колонка сатып алу;

- су алу урыннарын төзекләндерү (төзелеш материаллары сатып алу һәм хезмәтләр өчен түләү)

Экономия ясалган очракта, аерым мәсьәләләр буенча Түбән Көек авыл җирлеге башкарма комитетына җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итү өчен акча җибәрергә рөхсәт итәргә.

2. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Көек авыл җирлеге Яңа Шимбер авылында узган халык җыены нәтиҗәләрен авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә.

3. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Көек авыл җирлеге Яңа Шимбер авылында узган халык җыены нәтиҗәләрен Әтнә муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru. веб-адресы буенча һәм "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында" http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Түбән Көек авыл җирлеге башлыгы: Галиәхмәтов Д.М.